Мөслим гимназиясе укучылары газетасы

МӨСЛИМ ГИМНАЗИЯСЕ

# ТЫЛСЫМ+

№4 (72)

Гыйнвар, 2026 нчы ел




Бу санда

Гимназия сулышы 2

Хокук бозуларны ничек кисәтергә 2

Кыш күңелле узсын дисәң... 3

Үзеңне «ишетә» беләсеңме? 3

Студентлар белән очрашу 4

Истә калырлык кышкы каникуллар! 4

## ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ

*Гимназия яңалыклары - безнең рәсми сайтта https://edu.tatar.ru/muslum/muslumgym*

*Гимназия яңалыклары - социаль челтәрдә https://vk.com/gymnasiummus*

2026
ГОД ВОИНСКОЙ
И ТРУДОВОЙ ДОБЛЕСТИ
ХӘРБИ БАТЫРЛЫК һӘМ
ХЕЗМӘТ ФИДАКАРЬЛЕГЕ ЕЛЫ

### 2026 ел - Татарстанда “Хәрби батырлык һәм хезмәт фидакарьлеге елы”, Россиядә “Россия халыклары бердәмлеге елы”

2026 ел Россиядә Владимир Путин указы белән Россия халыклары бердәмлеге елы дип игълан ителде. Бу елның максаты - илдәге халыклар арасындагы дуслык, үзара аңлашуны ныгыту, милли бердәмлекне үстерү, шулай ук һәр халыкның мәдәни үзенчәлеген саклау.

Ватанны саклаучыларга һәм тыл хезмәтчәннәренә ихтирам йөзеннән, гражданнар бердәмлеген ныгыту максатында, 2026 ел Татарстанда «Хәрби батырлык һәм хезмәт фидакарьлеге елы» дип игълан ителде.

Бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның тууына 140 ел, герой-шагыйрь Муса Җәлил тууына 120 ел була. Безнең уртак бурыч – шагыйрьләрнең мирасын киң яктырту.



### «Ел укытучысы – 2026»

«Яшьләр һәм балалар» илкүләм проектының «Педагоглар һәм остазлар» федераль проекты кысаларында, Яр Чаллы шәһәренең 26 нчы гимназиясе базасында "Ел укытучысы" конкурсының зона туры узды.

Мөслим гимназиясенең биология укытучысы Бариева Ләйсән Фәхәметдин кызы конкурста катнашып, «Дәрес» һәм «Педагогик интервью» сынаулары кысаларында югары дәрәҗәдәге һөнәри әзерлек дәрәҗәсен күрсәтте.

Аңа киләчәктә дә уңышлар телибез! Без сезнең белән горурланабыз!

### Фән олимпиадасы көндәлеге







2026 нчы елның 9 нчы гыйнварыннан Татарстан Республикасы укучылары өчен 24 фән буенча Бөтенроссия олимпиадасының төбәк этабы старт алды

Укучылар өчен уздырыла торган фән олимпиадаларының рәсәй һәм республикакүләм турында Мөслим гимназиясе укучылары да катнаша. Куанырлык нәтиҗәләр дә бар.

10 нчы а сыйныфы укучысы **Галимова Эльза** (укытучысы Бакирова Г.Р.) мәктәп укучыларының инглиз теленнән «Олимпка юл» республика олимпиадасының йомгаклау этабында, рус телле балалар өчен татар теленнән узган республика олимпиадасында 6 нчы б, 8 нче а сыйныфы укучылары **Руслан Семенов, Ирина Асманова** (укытучылары - Ямалова Г.Ф.) призерлар булдылар.

Укучыларны һәм укытучыларны зур уңышлары белән котлыйбыз! Уңышлар дәвамлы булсын!

# ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ

## “Театр яктылыкка, нурга илтә”



Районда “Театр яктылыкка, нурга илтә” исемле муниципаль проект тормышка ашырыла. 17 мәктәп, 11 балалар бакчасында берничә ел дәвамында балалар театр коллективлары эшли.

Мөслим гимназиясендә башлангыч сыйныфлар укытучысы Ләйсән Фәхертдинова җитәкчелегендә “Яшь театр сөючеләр” түгәрәге алып барыла. Кечкенә артистлар быел Ләбиб Леронның “Аңгыра сарык җүләре” әкият-пьесасын сәхнәләштерде. Сценарий буенча сарык бәрәне юлында очраган һәр җанварны үзенең зирәклеге белән җиңәргә тиеш. Ләйсән Әхмәтгаяновна сценарийларны үзе дә яза. Сәләтле балаларны табып, заказга декорацияләр, сәхнә өчен кирәкле атрибутларны да ясата.

– Балалар театр сәнгатен ярата һәм бу юнәлешкә бик җайлы, җиңел кереп китә, чөнки сабыйлар әкият һәм маҗараларга ихлас күңелдән ышана. Күңелләрен биреп рольгә керү нәтиҗәсендә сәхнәгә куелган әсәрләр дә уңышлы килеп чыга. Мәктәп һәм театр арасында бик матур күпер төзелеп килә, – ди Ләйсән Фәхертдинова.

## "Россия бөркетләре" сафларына алу тантанасы



Гимназиядә "Россия бөркетләре"нә багышлау тантанасы үтте. Бу көнне аларның сафлары 60 балага артты.

“Россия бөркетләре” – "Алдынгылар" хәрәкәтенең 1-4 нче сыйныфларда белем алучы балаларны, аларның әти-әниләрен, укытучыларын, остазларны – урта һәм өлкән сыйныф укучыларын, хәрәкәт активистларын, эшчәнлекне оештыручы бик күп белгечләрне, проект җитәкчеләрен берләштерүче уникаль россиякүләм социаль активлык программасы.

Бөркетләр командасы – фикердәшләр һәм дусларның “Бергәләп белем алабыз, үсәбез һәм хыялланабыз!” девизы астында яшәүче ачык берлеге. “Россия бөркетләре” программасы белемгә, спорт казанышларына, иҗатка һәм фәнни ачышларга, танып белүгә, яңаны тәзүгә омтылучы, дөньяны тагын да яхшырак итәргә әзер ватанпәрвәр уллар һәм кызлар тәрбияләүгә шартлар булдыруны күз алдында тота.

# ХОКУК БОЗУЛАРНЫ НИЧЕК КИСӘТЕРГӘ?



*Актуаль тема*

Яшүсмерләр арасында хокук бозуларны булдырмый калуга юнәлтелгән чаралар бүген белем бирү оешмаларында алып барыла торган тәрбия эшенең мөһим бер юнәлеше булып тора. Тәрбия системасының даими үзгәреп торуы, бүгенге яшүсмерләрнең аралашу тирәлегенә хас үзенчәлекләр бу эштә заманча, аерым алганда интерактив методлар куллануны таләп итә. Федераль дәүләт белем бирү стандартлары буенча бүгенге яшүсмерне тәрбия бирү объектыннан бу процессның актив катнашучысына әверелдерергә кирәк. Интерактив методлар кулланганда, әлеге юнәлештә куелган максатка нәтиҗәле ирешеп була.

Гимназиядә хокук бозуларны кисәтү максатыннан профилактик отряд эшләп килә. Уку елы башында план төзелә, һәр ай саен төрле профилактик чаралар үткәрелә, хокук бозуларны кисәтү советы булдырылды.

Еллык эш планыннан чыгып, «Законнарны беләсеңме?», «Минем хокукларым һәм бурычларым» дигән темаларга сыйныф сәгатьләре, начар гадәтләргә каршы «Тәмәке белән бергә тартучы да яна», «Тәмәкесез бер көн», «Наркотиклар – тормышны җимерүче», «Алкоголизм гомерне кыскарта», «Наркомания – кешелек дошманы», «Алкоголь һәм аның зарары» дигән темаларга класстан тыш чаралар үткәрелә.

Участок һәм балигъ булмаган балалар белән эшләүче инспекторлар белән очрашулар оештырыла. Шуны билгеләп үтәргә кирәк: мондый отрядлар оештыру һәм аларның эшчәнлеге укучыларда хокукый культура, милли үзаң, патриотизм һәм Ватанга мәхәббәт хисе формалаштыруга булышлык итә. Мондый чаралар укучыларның гражданлык, социаль активлыгын һәм физик әзерлек дәрәҗәләрен арттыра.

***Миләүшә Әмирова,***
***Мөслим гимназиясенең социаль-педагогы***

## Белгеч әйтсә, хак әйтә



Хокук бозулар айлыгы кысаларында, юл хәрәкәте иминлеге инспекторы Диана Замировна 5 нче а һәм 5 нче в сыйныфы укучылары алдында чыгыш ясады.

Ул гимназиядә үз-үзеңне тоту кагыйдәләре, Уставны һәм эчке тәртип кагыйдәләрен үтәү зарурлыгы турында сөйләде.

Шулай ук, Интернет челтәрендә куркынычсызлык һәм таныш булмаган кешеләр белән аралашу кагыйдәләре турында аңлатып үтте. Очрашу барышында укучылар “Интернет челтәреннән куркынычсыз файдалану кагыйдәләрен бозу нәтиҗәләре” турында видеосюжет карадылар.

## КЫШ КҮҢЕЛЛЕ УЗСЫН ДИСӘҢ...



Менә, дуслар, 2026 елга аяк бастык. Эшләп, укып инде арылган, ә алда әле карлы, буранлы кыш... Мондый вакытта күпчелек кешеләрнең йөзендәге якты елмаюларның сүрелә баруы, кәефләребезнең бозылуы, ә тормышның исә тоташ караңгы булып тоела башлавы ихтимал.

Ә бит урамда ничек кенә салкын тоелмасын, жылы елмаю туңган йөрәкләрне эретә ул! Күңелең шат, елмаюың җылы булсын өчен нишләргә соң? Иң элек әлеге язманы укы, мин бит махсус синең өчен кайнар кышкы киңәшемне әзерләп куйдым!

**Китап укы! Файдалы!**

Киңәшем сиңа бераз баналь тоелыр, әмма аның тәэсире бик көчле, үтәве дә авыр түгел. Озын сүзнең кыскасы шул – китап укы.

«Фуу! Кирәк икән, мин интернет челтәрендә теләгәнемне укый, тыңлый, хәтта карый да алам», дияргә ашыкма. Китапларга өстән карау – яшүсмерләрнең канына сеңгән стереотип. Әлеге стереотиптан арынырга җиңел булмас, әмма син китап дөньясына бер чумасың икән, аннан кире чыга алмаячаксың. Аеруча салкын моңсу, озын кичләрдә тылсымлы, төсле яисә реалистик китап дөньясы сиңа ялгыз уйларыңнан арынырга, тәмләп ял итәргә булышачак.

*Үзең өчен кирәк булган китапны сайлап, мәгънәсен аңлап уку – иң мөһим эш.*

***К. Ушинский***

Чит ил галимнәре дәлилләве буенча, китап баш миен тынычландыра, авыр уйлардан арынырга булыша.

Укый башлау өчен Ауропа классикасын сайларга киңәш итәм. Шикләнмим дә, әлеге китаплар сиңа көчле тәэсир итәчәк.

Озын сүзнең кыскасы шул: тылсымлы китап дөньясы сиңа кабатланмас эмоцияләр кичерергә, геройлар белән үләргә, терелергә, гашыйк булырга һәм моңаерга мәҗбүр итәчәк.

***Замалова Зәринә,***
***“Тылсым+” газетасы мөхәррире***

Китап галим – телсез мөгаллим.

Китап – тормыш көзгесе.

Күп укыган күп белер.

Китап – белем чишмәсе.

Китапның белмәгәне юк.

Күп укысаң, күп белерсең.

Кояш җирне яктырта, уку кешене.

## ҮЗЕҢНЕ «ИШЕТӘ» БЕЛӘСЕҢМЕ?

***Бу сорауга җавап биргәнче, түбәндәге тестны узып кара. Нәтиҗәсен үзең күрерсең.***

1.«Юк» дип әйтергә авырмы?
– Әйе (2 балл)
– Юк (0 балл)

2. Хаталарыңа ничек карыйсың?
– Һәрвакыт бик борчылам, үземә ачулы булам (0 балл)
– Хата – тәҗрибә дип уйлыйм (3 балл)
– Үземә хаталандым дип уйларга рөхсәт тә итмим (0 балл)

3. Син үзеңне яхшы кеше дип уйлыйсыңмы?
- Әйе (2 балл)
– Юк (0 балл)

4. Үзеңне еш кына башкалар белән чагыштырасыңмы?
– Һәрвакыт (0 балл)
– Кайвакыт (1 балл)
– Бииик сирәк, бервакытта да чагыштырмыйм (2 балл)

5. Тәнкыйтькә карашың нинди?
– Бик борчылам (0 балл)
– Күңелле нәрсә түгел әлбәттә, ләкин түзәргә була. (1 балл)
– Миңа барыбер (2 балл)

6. Уңышка ирешүеңне күрә, аңлый, бәяли беләсеңме?
– Әйе, мин уңышларыма сөенәм. Шатланам. (2 балл)
- Һәрвакытта да түгел (1 балл)
– Юк, мин еш кына эш нәтиҗәләрен бәяләмим дә (0 балл)

7. Беренче эш итеп син башкаларның проблемаларын хәл итәсең, ә аннары вакыт калса, үзеңнекен.
- Әйе (0 балл)
– Юк (2 балл)

8. Еш кына укытучылар куйган билгегә риза булмыйсың.
– Бик еш (2 балл)
– Кайвакыт (1 балл)
– Бервакытта да (0 балл)

9. Авыр вакытларда үзеңне юата беләсеңме?
– Катлаулы сорау. Юктыр дип уйлыйм. (0 балл)
– Тырышам (1 балл)
– Мин һәрвакыт үземә-үзем булышам да, юатам да (2 балл)

10. Үз-үзеңне бик еш ачуланасың?
- Бик еш (0 баллов)
– Юк, сирәк (1 балл)
– Үземне бервакытта да ачуланмаска тырышам. (2 балл)

11. Син үзеңне мәхәббәткә, муллыкка, бәхеткә лаек дип ышанасыңмы?
– Әлбәттә (2 балл)
– Юк (0 балл)
– Әйтә алмыйм. (1 балл)

12. Кем беләндер аралашу ошамаса, син бу мөнәсәбәтләрне тиз өзәсең.
– Әйе (2 балл)
– Юк (0 балл)
– Өзәм, әмма аннан соң тагын аралаша башлый алам (1 балл)

13. Синең өчен башкалардан мактау сүзләре ишетү мөһимме?
– Әйе (0 балл)
– Кайвакыт (1 балл)
– Юк (2 балл)

***Психология. Тәрбия***



**Нәтиҗә**

*21-27 балл.* رзбسر шакт ый югары дәрәҗәдә. Син үзеңне рәнҗетергә юл куймассың. Үзеңне «ишетә» беләсең. Теләкләреңә, тойгыларыңа таянып карарлар кабул итәсең.

11-20 балл. Үзбәяң диңгездәге су күтәрелеше һәм су чигенешләрен хәтерләтә. Әйләнә-тирәдә барысы да яхшы булса һәм эшләрең дә проблемаларсыз гына барса, син үзүзеңнән канәгать. Ниндидер бер өзеклелек килеп чыкса, син беренче чиратта үзеңне тәнкыйтьли башлыйсың, хатаны үзеңнән эзлисең. Үзбәяңне күтәрергә кирәк.

0-10 балл. Син үзеңне бөтенләй диярлек бәяләмисең. Еш кына эчке тәнкыйтьчеңнең тавышын «ишетәсең», ул тагын барысын да дөрес эшләмәвең турында искәртеп тора. Син моңа күнегеп беткәнсең. Эчеңдә киеренкелек, сагыш һәм чарасызлык күп. Тиз арада үзеңне үзгәртү өстендә эшли башла.

## СТУДЕНТЛАР БЕЛӘН ОЧРАШУ

***Традиция буенча Мөслим гимназиясе үзенең чыгарылыш укучыларын җыйды.*** Быел бу көн 29 нчы гыйнварга туры килде.

Кичәне оештыручы Альфира Әлфисовна, Гөлшат Марсовна һәм 9 нчы в сыйныфы укучылары очрашуга килгән элеккеге укучыларыбыз өчен кызыклы һәм истәлекле булсын дип, зур тырышлык куйдылар.

***Әхмәтҗанов Фирзәр, “Чыгарылыш - 2025”:***
“Студент ул – актив тормыш позициясен алып баручы кеше”.

Студентларыбыз укулары, сайлаган профессияләре, яңа коллективта очраган авырлыклар һәм аларны җиңү юллары турында сөйләделәр. Укучылар үзләре өчен бик күп файдалы мәгълүмат алдылар.

Студентлар укытучылар коллективына төпле белем биргәннәре өчен зур рәхмәт җиткерделәр. Очрашуга килүчеләр уеннарда бик теләп катнаштылар, концерт номерлары ямь өстенә ямь бирде.

Еллар узган саен гимназия белән ара ерагая, ләкин мәктәп еллары турындагы истәлекләр югалмый.






## ИСТӘ КАЛЫРЛЫК КЫШКЫ КАНИКУЛЛАР!

***Менә кышкы каникуллар узып китте.***

Каникуллар - ул сәламәтлекне ныгыту, яңа көч туплау, иҗади сәләтләрне үстерү, шәхес формалашуында әһәмиятле чор. Шуңа күрә бу чорда балаларның һәм яшүсмерләрнең буш вакытларын дөрес файдалануга, кышкы каникулда ялларын нәтиҗәле һәм файдалы оештыруга сыйныф җитәкчеләре, ата-аналар комитетлары игътибар бирде.

Укучылар тау шуарга, табигатьтә булырга, музей, китапханәдә, район мәдәният йортында үткән чараларда катнашырга, сыйныфташлары белән кино карарга һәм “Дуслар клаб”тагы пицца, роллдар белән сыйланырга да өлгерделәр.











ТЫЛСЫМ+
Гыйнвар, 2026 нчы ел
№4 (72)
*Мөслим гимназиясе укучылары газетасы*

**Баш мөхәррир:** Солтанова Г.М.
**Техник редактор:** Кадыйрова А.Р.

**Мөхәррир:** Замалова Зәринә
**Корректорлар:** Хәйруллина Диләрә
**Корреспондентлар:** Насырова Мәрьям, Фәхрәзиева Алинә
**Дизайнер:** Мостафина Рәйлә
**Компьютерда җыючылар:** Вагыйзов Айзат, Сәләмов Наил

***2014 нче елдан айга бер тапкыр нәшер ителә***

**Гамәлгә куючы:**
Мөслим гимназиясе укучылар иҗат үзәге
**Адрес:** Мөслим, Кооператив урамы, 170а
**Сайт:** https://edu.tatar.ru/muslum/muslumgym
**Электрон адрес:** tilsim2014@yandex.ru
**Формат:** А4 (А3)
**Тираж:** 100